# Караш

*…ЯЛТ ИТТЕР КҮҢЕЛЕҢНЕ СЫЗЫП АК НУР БЕЛӘН!*

**1999 нчы елның 19 нчы маеннан чыга.**
**№ 1 2016. Октябрь - ноябрь**
**«НӘШРИЯТ ЭШЕ» түгәрәге**

**"*Нәшрият эше "Караш"* түгәрәге "Ялт иттер күңеләңне, сызып ак нур белән!" дигән девиз астында эшли. Лашман урта мәктәбендә инде күп еллардан бирле әдәби иҗат түгәрәкләре эшләп килде. Төрле елларда төрле исем астында эшләп килсәләр дә, алар һаман бер максатны – укучыларда әдәбиятка, сәнгатькә хөрмәт тәрбияләүне, талантлы укучыларга юл күрсәтүне, иҗат эше белән кызыксынуны үстерүне күз алдында тотып эшләде.**

**Без авазлардан сүзләр, ә сүзләрдән чәчәкләр тезәбез дә, балачак дигән серле аланга сибәбез; ә анда безгә иш булып, йөзләгән, меңләгән чәчәкләр калкып чыга. Әлеге алан илһамият дигән серле дөньяга әйләнә дә, һәркемнең күңеленә илаһи нур чәчә. Без әнә шул нурлар эчендә коенабыз. Күңелебез белән иҗади утта җылынабыз…**

**Инде менә 1999 нчы елның 19 нчы маеннан бирле мәктәбебезнең үз газетасы чыгып килә. "Нәшрият эше. "Караш"" түгәрәге әгъзаларыннан оештырылган редколлегия составы уңышлы гына эш башкара. Газета ике атнага бер тапкыр чыгарыла. Анда укучылар үзләрен борчыган мәсьәләләрне күтәреп чыгалар, иҗат эше белән шөгыльләнәләр, каләмнәрен үткерлиләр.**

**"*Нәшрият эше "Караш"* түгәрәге балаларны халкыбызның рухи-әхлакый идеалларына китерергә, аларда югары сөйләм культурасы формалаштырырга, иҗади сәләтен үстерергә, мөстәкыйль уйларга һәм эшләргә омтылышын канәгатьләндерергә тиеш дип саныйм мин. Түгәрәктә танып-белү эшчәнлеге аралашу формасында оештырыла.**

ОКТЯБРЬДӘ… олимпиадаларның мәктәп туры тәмамланды. Әлеге турда җиңүче укучыларыбызга мәктәп данын район турында яклау өчен күп көч куярга туры киләчәген аңлап, аларга уңышлар телибез. (Кемнәр ничек чыгыш ясавы турында мәгълүмат мәктәп сайтында урнаштырылган)

ОКТЯБРЬДӘ… мәктәптә күп кенә түгәрәкләр эшли башлады. Укучыларга үз сәләтләрен тагы үстерүгә мөмкинлекләр ачылды, кулдан ычкындырмагыз!!!

ОКТЯБРЬДӘ… традицион Көзге бал һәм "Уңыш бәйрәме" гөрләп узды.

НОЯБРЬДӘ… олимпиадаларның район туры башланып китә. Барыбызга да уңышлар!!!

НОЯБРЬДӘ…мәктәбебездә республикакүләм семинар узачак.

## БУ САНДА

… Бары чыгып киткәч кенә аңлыйсың икән: мәктәптә укыган дәверләр иң рәхәт, иң кызык, иң җайлы вакытлар булган. Һәр укытучы сиңа әниең кебек бары яхшы теләктә генә торган. Укыйсы да укыйсы гына бит!!! Юк шул, зарланабыз, уфырабыз…. Ә нәкъ менә мәктәптә алган белемнәр барысы да киләчәктәге белемнәр өчен нигез була икән. Кем соң өй нигезен "ярап торыр әле шунда!"дип кора? **"Хыялларга юл ярганда"**

**…Иртә белән Әтәч үз командасын ияртеп инешкә киткән, ди. Ләкин бер тавык та суга керергә базмый икән. Ә Бибичуар тиз генә яр буенда үсеп утырган үги ана яфракларын ике катлап аякларына бәйләгән дә суга сикереп тә төшкән. Башка тавыкларның: "Титибаш, батасың ич!" – дигән сүзләренә исе дә китмичә, башын горур күтәреп йөзеп тә киткән. Әтәч аның кыюлыгына шаккаткан, аны иң яраткан хатыны дип игълан иткән. Менә шулай, кайвакытта күзәтүчән һәм хәйләкәр булсаң, уңышка ирешәсең. ("Мин кулыма тәүге кабат каләм алам" )**

***…Һәр сөйләшнең үзенә генә хас фразеологизмнары да бар, алар бу сөйләшләрнең йөзек кашлары күк кабатланмас лексик хәзинә булып торалар. Кызганыч, әлеге хәзинәгә тулысынча ия булган өлкән буын сафы сирәгәя бара, алар белән бергә лексик хәзинәбез дә онытыла бара. Безнең буын әдәби әсәрләрдә, әдәби сөйләмле тапшыруларда тәрбияләнә. Җирле сөйләмебезне бу күренеш кысырыклый бара….***

("Бу тарихка шулай кереп калган")

# *Хыялларга юл ярганда...*



Җил-давыллардан, эссе кояшлардан яшь агачны нысыганчы зур, олпат, нысыган агачлар саклый. Мин дә язмышыма үз тормышымда шундый хөрмәткә лаек остазларым булуына мең рәхмәтле.Туган авылымнан, мәктәбемнән, канат нысытып, читкә очкач та күңелемдәге рәхмәт хисем зурая гына бара. Һәр иртәне үзем теләгән уку йортының бусагасын атлап үткәндә, мин хыялларым чынга ашканга шатланып туя алмыйм. Күңелемнән үземнең остазларымны барлыйм. Фаиз абый... Аның тәкъдиме белән 16 нчы сентябрьдә, алты яшем тулар-тулмас, укырга килүем минем язмышымны үзгәртүдә беренче зур адым булгандыр. Өметем өзелеп, дөньядан ваз кичеп ятканда җитәкләп диярлек бассейнга китереп йөзәргә өйрәттегез. Кечкенә генә уңышларымны да күрә белеп, зур уңышларга юл ачтыгыз. Сезнең белән ярты Татарстанны йөреп чыктык бит без. Сынмаска, бирешмәскә, җиңәргә һәм җиңелә белергә өйрәттегез, Фаиз абый!

Җил-давыллардан, эссе кояшлардан яшь агачны нысыганчы зур, олпат, нысыган агачлар саклый. Мин дә язмышыма үз тормышымда шундый хөрмәткә лаек остазларым булуына мең рәхмәтле.Туган авылымнан, мәктәбемнән, канат нысытып, читкә очкач та күңелемдәге рәхмәт хисем зурая гына бара. Һәр иртәне үзем теләгән уку йортының бусагасын атлап үткәндә, мин хыялларым чынга ашканга шатланып туя алмыйм. Күңелемнән үземнең остазларымны барлыйм. Фаиз абый... Аның тәкъдиме белән 16 нчы сентябрьдә, алты яшем тулар-тулмас, укырга килүем минем язмышымны үзгәртүдә беренче зур адым булгандыр. Өметем өзелеп, дөньядан ваз кичеп ятканда җитәкләп диярлек бассейнга китереп йөзәргә өйрәттегез. Кечкенә генә уңышларымны да күрә белеп, зур уңышларга юл ачтыгыз. Сезнең белән ярты Татарстанны йөреп чыктык бит без. Сынмаска, бирешмәскә, җиңәргә һәм җиңелә белергә өйрәттегез, Фаиз абый! .

Күңелемдәге изге теләкләремне, ихлас рәхмәтләремне шулай ук Рушания апага, Шакирзянова Рәзидә апаларга аерым җиткерәсем килә. Хәтерлисезме, 2010 нчы елның 31 нче декабрен. Күз ачкысыз буран. Сез киң күңелле кыш бабай һәм мөләем кар кызы күңелсез больница палатасына яңа ел һәм өмет алып килдегез. Бу бит сезнең олы йөрәклелегезнең бер билгесе. Бәлки ул вакытта балалык белән рәхмәт тә әйтә алмаганмындыр. Бүген баш иеп сезгә рәхмәтемне җиткерәм. Ярдәмгә мохтаҗларга ярдәм итәргә, авырлыкларны бүлешә белергә мин сездән өйрәндем. Сабыр булырга Земфира ападан, таләпчәнлеккә Резеда апа Салаховадан, үзсүзлелек һәм максатчанлыкка Флера ападан, җаваплылыкка Гүзәлия ападан, оптимистик рухка Рәмзия ападан, вакыт бәясен белергә Илдар абыйдан, укысаң белеп була икәнлегенә Ильхам абыйдан өйрәндем мин. Бу сыйфатлар миңа тормыш дигән олы диңгездә тайпылмыйча үз юлымнан максатыма барырга нык ярдәм итә. Бары чыгып киткәч кенә аңлыйсың икән: мәктәптә укыган дәверләр иң рәхәт, иң кызык, иң җайлы вакытлар булган. Һәр укытучы сиңа әниең кебек бары яхшы теләктә генә торган. Укыйсы да укыйсы гына бит!!! Юк шул, зарланабыз, уфырабыз.... Ә нәкъ менә мәктәптә алган белемнәр барысы да киләчәктәге белемнәр өчен нигез була икән. Кем соң өй нигезен "ярап торыр әле шунда!"дип кора? Әле мәктәптә укып йөрүче яшьтәшләремә дә шулай мөрәҗәгать итәсем килә: һәр сәгатегезне, минутыгызны киләчәк өегезнең "фундаментын" ныклап кору өчен тырышыгыз.

Ә мин бүген студент. Иңемдәге ак халатым кебек ак хыялым – табиб булуга беренче сукмагымны салам. Чыгарылыш имтиханнарын тапшырып, хыял түремдә йөрткән уку йортының бюджет бүлегенә укырга керүемдә, әлбәттә, иң зур өлеш минем укытучыларымныкы. Рәхмәт сезгә, минем Укытучыларым! Авыр, кайвакытта рәхмәтсез дә, бәяләнмичә дә калган эшегездә күркәм сабырлык, нык сәламәтлек, аңлаучан тырыш укучылар телим.

Ә "Караш"ның яңа төркеменә иҗади уңышлар юлдаш булсын, эзләгез, үзегезне табыгыз!!!

2016 нчы елгы чыгрылыш укучысы,
"Караш" ның эксҗитәкчесе,
ИГМА студенты Рания Газимҗанова

# Мин кулыма тәүге кабат каләм алам...



Гайсина Русинә 6 нчы сыйныф укучысы

### *Көтеп алган яңгыр.*

Борын-борын заманда бик тылсымлы болыт яшәгән ди. Нинди генә авырлыклар очраса да, үзенең тылсымын эшкә җиккән ди. Ләкин тылсым көчен үзенә генә түгел, ә башкаларга да ярдәм иткәндә кулланырга уйлаган. Шулай итеп, башкаларны күбрәк шатландырырга теләгән.

Шулай бер көнне агым уңаена акканда, җәелеп яткан авыллар, шәһәрләргә игътибар иткән. Бу авыллар, шәһәрләр бик боек булып күренгән аңа. Бигрәк тә авыллар. Яхшылап караса әле җәй булуга карамастан анда барлык яшеллек көеп беткән. Тереклекләр башларын аска иеп, моңсуланганнар. Күрәсең монда күптән яңгыр яуганы юк икән. Тиз генә үзеннән алга киткән иптәшләрен куып җиткән хәлне аңлатып, ярдәм итәргә теләвен әйтткән. Бу эштә аларның да ярдәм итүләрен үтенгән.

- Безнең яңгыр яудырырга бер дә теләгебез юк, - дип җавап биргәннәр аңа.
- Халыкны мондый хәлдә ташлап китәргә ярамый, алар бит бездән ярдәм көтеп, барысы да күккә төбәлгән, - дигән тылсымлы болыт.
- Соң күрсәт тылсымыңны, әгәр хәлеңнән килсә, - дигәннәр барсы бер тавыштан.

Тылсымлы болыт монда үзенең генә хәле җитмәячәген, яңгырның күп җиргә кирәклеген аңлатса да аңардан көлгәннәр генә, янәсе мактанчык, булдыксыз.

- Юк, минем тылсымым белән беркайчан да мактанганым юк. Ул сәләт миңа ата- бабадан калган.
- Я соң, күрсәт сәләтеңне,- дип юлларын дәвам иткән көнче болытлар.

Тылсымлы болыт тәвәкәлләгән. Аның бик тә, бик тә ярдәм итәсе килә. Ул юлыннан борылып кирегә йөзәргә керешә. Башка болытларга бәрелә, сугыла, аңа юл бирмиләр. Аларның бәрелүеннән көчле күк күкрәү барлыкка килә. Ә бу халыкта тагын өмет уята.

Болытлар үз юлыннан гына бармаучы бу болытны орышалар, анардан көләләр. Ә тылсымлы болыт алар белән көрәшә-көрәшә корылык хөкем сөргән бу урынга килеп җитә. Тылсымлы сүзләрен кабатлый-кабатлый тирә -якка кулларын селкә. Бу селтәүләрдән йолт-йолт яшен яшни һәм ниһаять, яңгыр яварга тотына. Әкрен генә, тәмен белеп кенә бик озак ява яңгыр. Тылсым көченә ышанмаучылар да гаҗәпләнерлек була бу. Барча тереклек туйганчы су эчә, рәхмәт укый. Ә тылсымлы болыт башкаларга ярдәм итүенә сөенеп бетә алмый. Әле һаман шулай тилмереп утыручылар юкмы икән дип каранып йөри ди.

Гайсина Русинә. 6 нчы сыйныф укучысы

### Хәйләсез дөнья файдасыз.



Мөхәмәтҗанова Эвелина
6 нчы сыйныф укучысы

Бер йортта, кайсыдыр бер заманда яшәгән ди, булган ди бер әтәч гаиләсе. Бу гаилә зур булган, чөнки бу әтәчнең хатыннары гына да 15 ләп икән. Ләкин Әтәчның хатыннары Бибитавыкҗамаллар бар рәхәткә шөкер итеп яши белмәгәннәр. Һәр көнне үзара талашалар, кай көннәрдә бу талаш сугышка да әйләнә икән. Талашның төп сәбәбе – кайсы тавык иң матуры, иң булганы, ягъни Әтәчкәйнең иң яратканы икәнне ачыклау. Ярар. Көннәр үтә торган, Әтәч бу шау-шудан тәмам туйган. Бер көнне йортта кабат тавыш купкач, ул койма башына менеп утырган икән. Шулай моңаеп утырганда, аның башына бер гаҗәеп идея килгән: “Тавыккайларым, җаныкайларым, барыгыз да бик уңган, барыгыз да бик булган, ләкин мин йөзә белгән тавыкбикәне генә яратам шул. Кем иртәгә әнә шул бакча башындагы инешне йөзеп чыга, шул сөекле бикәм була! Йөзә алмаучылар башка авызын да ачмый!”- дигән ул. Тавыклар шым булганнар. Башларына кайгы төшкән. Тик бер тавык кына – Бибичуар гына шыпырт кына инеш ягына киткән. Ары барган, бире килгән, шундый кызык нәрсә күргән: шунда коенып уйнап яткан малайлар аякларына әллә ни кияләр дә, сызгыртып йөзеп китәләр икән! Әнә үрдәкләрнең үз аягы да шундый нәрсәгә бик охшаш. Бер аларга, бер үзенең аякларына карап уйга баткан Бибичуар. Һәм...

Иртә белән Әтәч үз командасын ияртеп инешкә киткән, ди. Ләкин бер тавык та суга керергә базмый икән. Ә Бибичуар тиз генә яр буенда үсеп утырган үги ана яфракларын ике катлап аякларына бәйләгән дә суга сикереп тә төшкән. Башка тавыкларның: “Титибаш, батасың ич!” – дигән сүзләренә исе дә китмичә, башын горур күтәреп йөзеп тә киткән. Әтәч аның кыюлыгына шаккаткан, аны иң яраткан хатыны дип игълан иткән. Менә шулай, кайвакытта күзәтүчән һәм хәйләкәр булсаң, уңышка ирешәсең.

# шигъри почмак

**Кызык уен.**

Өйдә берүзем калгач,
Мин кызык уен таптым.
Һәр сүзнең дустын эзләп,
Башымны ватып яттым.
Менә, мәсәлән, кызык.
Дус була аңа сызык.
(Бик озак булса кызык,
Ахырдан була сызык)
Иләк-чиләк, баш-каш-таш,
Яки менә гөрләвек.
Бусы бераз авыррак,
Ләкин табам – чикләвек!
Тагын була беләзек.
Беләзеккә дус нәзек.
Йөрәк сүзенә беләк,
Беләк сүзенә көрәк.
Белергә бик күп кирәк!
Һәм менә шуның өчен
Мин бик тырышып укыйм,
Куямын бөтен көчем!



***Җиләк балы***

*Әбием сыйлый мине:*
*“Бу, улым, юкә балы!”*
*Юкә балы? Һич аңламыйм,*
*Анысы ни була тагы?*
*Юкә ни диеп сорагач,*
*Әйттеләр, ул – бер агач.*
*Балны бик күп бирә икән*
*Җәй көне чәчәк аткач.*
*Чәй эчкәндә коймак белән*
*Юкә балы тәмле дә.*
*Ләкин миңа ни өчендер*
*Җиләк балы тәмлерәк!*
*Җиләк балы ни дисезме?*
*Шуны да белмисезме?*
*Әби аңа “вәринҗе” ди,*
*Кемдер әйтә кайнатма.*
*“Җиләк балы” матуррак,*
*Һәм мин аны яратам.*

Газимҗанов Нурфат 2 нче сыйныф укучысы



**Яратам мәктәбемне!**

Мина берсе сорау бирде.
Бик сәер сорау иде.
“Нигә син яратасың
Мәктәбегезне?” - диде.
Озак уйлап тормадым мин,
Шундый җавап кайтардым:
Ничек инде мәктәбемне
Яратмаска булдырыйм?
Өйрәтә бит ул безне
Укырга һәм язарга.
Монда өйрәндем әле мин
Балык кебек йөзәргә.
Чыңлы кынгыравы белән
Каршы ала һәр иртә.
Алда кирәк булыр эшнең
Һәммәсенә өйрәтә.
Анда укый минем гаиләм
Минем гаиләм-дусларым.
Уйнап- көлешеп йөрибез
Һәрбер тәнәфес саен.
Минем хисләрем белән
Тулы нәни йөрәгем.
Яратмаска мөмкин түгел –
Ул бит минем мәктәбем!

**Гатина Фәйрүзә 10нчы сыйныф.**

***Китап***

***Яктылыкка юл күрсәтер,***
***Начарлык тәкъдим итмәс.***
***«Тәртипсезлек сукмагында***
***Йөрмә, - дияр, - кирәкмәс!»***
***Кирәк булса булышыр ул,***
***Авыр хәлдән чыгарыр.***
***Аптыраган кешегә***
***Ярдәм кулын ул сузар.***
***Белем диңгезендә йөзә***
***Китап белән һәр бала.***
***Син дә дустым калышма,***
***Китаплар укып кара.***

***Газимҗанова Гөлинә***
***10 нчы сыйныф***

**“Әнкәй”**

Ул бит безгә һәр көн назын бирә,
Ул бит безне карап үстергән.
Туган көнебездән “алмам” диеп,
“Алтын җимешем” дип үстергән.
Нурлы якты йөзе белән безгә карап,
Бәхет-шатлык кына тели ул.
“Балам “ диеп безне назлап тора,
Җылы йомшак кулы белән ул.

“Сау бул, көз!”

Яңгырлары белән елый-елый
Саубуллашыр инде тиздән көз.
Сары шәлен тыйнак кына ябып,
Шыпырт кына качар инде көз.
Сары сагышларны алып китеп,
Ап-ак матур кышны чакырыр.
Ә тагын төгәл бер ел үткәч
Алтын табигатен кайтарыр.

***Кышкы кич***
***(этюд)***

***Яратам мин кышның кичен.***
***Яратам саф һавасын.***
***Һич онтылмый матур кышның***
***Тылсымлы матур чагы.***

***Ай яктысы җиргә төшеп***
***Ялтырата карларны***
***Бу карлар хәтерләтә***
***Матур асылташларны.***

***Тыныч бу кич, матур бу кич.***
***Бураны да юк аның.***
***Шушы матурлыкка карап***
***Моңланып утырамын.***



Срyртдинова Ләйлә 10 нчы сыйныф укучысы

*Иң күңелле мизгелләр.*



Бу ел минем һөнәри яктан эшчәнлегемдә бик уңышлы, нәтиҗәле ел булды. Шушы уңышларым арасында иң күңелдә калганы, исемә төшкәч тә, күзләрем "көлеп", авызым "ерылып" китә торганы "Мәгариф" журналы тарафыннан оештырылган "Авыл укытучысы -2016" бәйгесендә катнашу булгандыр. Бүгенге көннәрдә дә, ниндидер күңел төшенкелеге, күңелемдә авырсыну сизсәм, конкурс узган көннәрдәге фотосурәтләрне ачам да, карап утырам. Шул минутларда кичергәннәремне, шатлык , горурлык хисләрен , үзебезгә карата ягымлы, итагатьле, "аксөякләр" генә булдыра алган җылы да, ниндидер хөрмәтле дә мөгамәләне, карашны кире үзем аша үткәрәм дә , җаным тынычланып китә. Һәм кабат тәнемә көч керә һәм мин , рухланып, тагын үз хезмәтемә тотынам. Ә бит укытучының эше егерме дүрт сәгать эшләсәң дә, бетә торган түгел. Шуңа безгә яшәү көче, рухи азык һәрдаим кирәк. Шул вакытта үземнең авырсынмыйча , җәй көне кырыкмаса кырык төрле эшкә дә игътибар итмичә , катнашыйм әле дип, беренче турга язмамны җибәрүем өчен бик шатланам.

Шунысы кызык, конкурс шартлары белән беренче тапкыр танышканда ,эшләр 31 нче июнь 23 сәгать 59 минутка кадәр кабул ителә дигән җөмлә минем күңелемә кереп калган . Төнлә кем эш җибәрер икән, дип уйлап куйганым да бик хәтеремдә. Көннәр уза тора, мин акрын гына әзерләнәм һәм менә нәкъ шул кичтә "келт итеп" бүген бит соңгы көн икәнлеге исемә төште. Һәм төнге хат җибәрүче үзем булып калдым да. Шул сәгатьтә авырсынмыйча, эшемне җибәрүемә соңыннан бик куандым . Һәм нәтиҗә дә чыгардым: катнашасы килгән конкурсыңа эшеңне иртәрәк җибәрергә, сузмаска кирәк икән, дидем. Бу нәтиҗәмнең бәлки ,кемгә дә булса файдасы тияр.

Икенче турга җибәрәсе эшемне авырсынмыйча башкардым. Анысы да "очып " киткәч , "инде өченче турга да чыксам иде" дигән ниндидер тәмле өмет-хыял күңелдә бөреләнде. Ә мастер - класс ярышына килү үзе бер бәйрәм булды. Бу көнне иртәнге сәгать җидедә мин инде конкурс узасы бина янында басып тора идем. Конкурсның бу этабында башка район, башка фән укытучыларының да эшен күзәтү бәхетенә ирештем. Алар һәркайсы бик тырышып әзерләнгән, күп еллар эшләүче укытучылар булып чыкты. Шунысы кызык, без бер -беребезне әллә кайчан белгән кешеләр кебек бик җиңел аралашып киттек. Алга китеп булса да әйтим әле, без бүген дә алар белән элемтәдә торабыз. Димәк, бу конкурс республикабызның төрле төбәкләрен дә дуслаштыра икән! Мастер -класс вакытында дә ярдәмчеллек, һәрберебезнең уңышына шатланып тору, эчкерсез аралашу булгач, бик рәхәт булды. Биредә үз дәресләреңдә куллану өчен күп төрле мәгълүмат алуга юл ачыла. Мин аларның күбесенең чыгышын , кирәк вакытта файдалану өчен, үз видео-камерама да яздырып бардым. Шуның белән беррәттән , кимчелекле яклар да күренә икән. Яктан караганда рәхәт бит ул.Монда ,мәсәлән, кайбер укытучыларның рус сүзләрен кертеп сөйләшүләре күзгә бәрелеп тора. Эчеңнән генә, болай эшләмәскә тырышырга икән ,дип уйлап куясың. Нәтиҗәләр ясалып, Галимова Резеда - өченче урын дигән игъланнан соң, минем бөтен дөньяга "Ур-ра!" ,-дип сөрән саласым килде. Шатлыгымның иге-чиге булмады. Юлның озынлыгы үзем эшләгән коллектив укытучылары, директор, директор урынбасарының котлаулары белән сизелмичә дә калды.

Чакыру килеп төшкәч, тагын бер дулкынлану кичердем. Көтү шатлыгы белән көннәр тиз узды. Ә 6нчы октябрь көнне иртән телевидениедән башланган көн , гүзәл бер мизгел булып узып китте. Биредә пресс-конференция турында әйтеп узмый булмый. Минем мондый чарада беренче тапкыр гына катнашуым иде. Ул шулай ук, бик җаваплы чара икән.Әлеге чараны интернет аша караган кайбер хезмәттәшләрем, "Без синең урында булсак, елап та җибәргән булыр идек", дип соклануларын белдерделәр. Журналистлар белән әлеге очрашу бик зур әһәмиятле чара булып, күңелдә калды. Иң соңыннан, Мәгариф министрыннан котлау ишетү, иңгә салынган тун -әйтеп бетергесез куанычлы хисләр калдырды. Хәтта , әлеге хисләр ташкынынннан башлар әйләнеп китте.

Әгәр дә мин бу язмамда үземнең хезмәттәшләрем турында бер сүз дә әйтмәсәм, дөрес булмас иде. Минем бу җиңүгә ирешүемдә аларның өлеше дә бик зур .Чөнки бер генә хезмәт тә берүзең генә булганда нәтиҗә бирми. Безнең мәктәптә көчле укытучылар эшләгәнгә дә , бу конкурста җиңү яулаганмындыр мин. Аларга мин чиксез рәхмәтле.Мин әлеге язмамны кемгәдер ярарга тырышып язмадым. Күңелемнән чыккан ихлас хисләрем җиңел генә ак юлларга төшеп ятты. Бу сүзләрем әлеге конкурсны оештыручыларга, аны зурлап үткәрүчеләргә зур рәхмәт булып барып җитсен иде. Тагын да шундый конкурсларны оештырсыннар, сау-сәламәт булып, һәр көннән тәм табып яшәсеннәр иде!

**Резеда Галимова. Башлангыч сыйныфлар укытучысы**

# Беләсеңме? Ишеттеңме? Исеңдә тот...

**Өйрәтәләр МәКтӘпЛәРдӘ, МәКтӘпЛәРдӘ...**



Мәктәп – безнең икенче йортыбыз, анда безнең дусларыбыз, яраткан укытучыларыбыз. Кемнәрдер мәктәпкә укырга дип, кемнәрдер дуслары белән күрешергә дип йөрсә, икенчеләре тәмле-тәмле ризыклар, пирожкилар өчен йөри кебек миңа. Инде мәктәп темасына кереп киткәч, бераз мәктәп турындагы кайбер мәгълүматлар белән дә танышып китик. Безнең өчен 1 сентябрь уку башланган көн булып саналса да, кайбер илләрдә ул бөтенләй башка дата. Мәсәлән, Испаниядә мәктәп бусагалары кырлардан уңыш җыелып беткәч кенә ачыла, ә Дания укучылары август урталарыннан ук укый башлыйлар икән. Ә менә Япониядә укуны бик күңелле итеп кабул итәләр һәм уку да аларда 1 апрельдә башлана. Иң борынгы уку йорты – Фес шәһәрендә урнашкан Карауин мөселман университеты икән. Бу университет б.э.к. 859 елда ачылган булган. Иң күп укучыны үзенә туплаган мәктәп Һиндстанда. Анда 28000 укучы белем ала. Иң кыйммәтле мәктәп - “Халыкара яшь туташлар һәм әфәнделәр мәктәбе”. Бу мәктәптә уку аена 77,5 мең доллар, ягъни 2 500 000 сум тирәсе тора. Чыгарылыш укучыларының иң зур очрашуы Алманиядә була. Анда 2 500 кеше килә. Америка яшүсмере уку өчен якынча 12 000 сәгать сарыф итсә, телевизор карауга аның 14 000 тирәсе сәгать әрәм ителә. Безнең илдә иң югары билге “5”ле, ә иң түбәне “1” ле саналса, Чехиядә киресенчә икән. Аларда “1”ле алу бик сөенечле хәл. Ә инде ашханәгә килсәк, статистика буенча малайлар ашханә өчен акчаны кызларга караганда 3 тапкыр күбрәк тоталар икән. Безнең мәктәптә дә малайларның пирожки өчен үлеп торулары моңа бер дәлилдер.

**Белеп тор! Зыян итмәс.**

-Еланнарның 25 меңгә кадәр теше булырга мөмкин.

— Кешенең гомере буена коелган керфекләренең гомуми озынлыгы 30 метрга җитә.

— Дөньяда һәр кешегә миллион кырмыска туры килә.

— Фил – сикерә белми торган бердәнбер хайван.

— Елан өч ел рәттән йоклый ала. Кеше елына уртача 1460 төш күрә

— Аю ат кебек үк тиз чаба ала.

**Минә сиңа мә!!!**

Алмаз дустына зарлана икән: - Бик куркам әле мин. Әти яңа машина алды, искесен сатты. - Шуннан нәрсә була инде? - Кичә әни яңа бәби сатып алды...

Алмаз зоопаркта жирафны күреп: - Их, минем дә шундый муеным булса, күчергәнемне беркем дә күрмәс иде!

- Апа, минем көндәлеккә “2”ле куегыз әле... - Ә ни өчен мин сиңа “2”ле куярга тиеш соң? - Әти бер көнне: “Әгәр “2”ле алсаң, мин сиңа күрмәгәнеңне күрсәтәм диде. Ә минем аквапарк күргәнем юк...

## *БУ ТАРИХКА ШУЛАЙ КЕРЕП КАЛГАН*

*(Лашман авылының үзенчәлекле лексик байлыгы рубрикасына)*

Һәр төбәкнең үзенә генә хас үзенчәлекле сөйләм теле бар. Аның диалектлар, сөйләшләр диләр. Бу сөйләшләр бер-берсе белән фонетик, морфологик, синтаксик үзенчәлекләр белән аерылып торалар. Һәр сөйләшнең үзенә генә хас фразеологизмнары да бар, алар бу сөйләшләрнең йөзек кашлары кук кабатланмас лексик хәзинә булып торалар. Кызганыч, әлеге хәзинәгә тулысынча ия булган өлкән буын сафы сирәгәя бара, алар белән бергә лексик хәзинәбез дә онытыла бара. Безнең буын әдәби әсәрләрдә, әдәби сөйләмле тапшыруларда тәрбияләнә. Җирле сөйләмебезне бу күренеш кысырыклый бара.

Әбием белән сөйләшкәндә ул әйткән гыйбарәләрне еш кына аңламыйча кабат сорыйм. Ул миңа аларны иркенләп аңлата, сөйләмебезгә ничек килеп керү тарихын сөйләп бирә. Баксаң, авылыбыз җирлегендә генә дә күпме үзенчәлекле лексик хәзинә ята икән! Аларны тупларга, өйрәнергә, алдагы буыннарга әманәт итеп тапшырырга кирәк, чөнки аларда безнең авылыбызның тарихы, кызыклы шәхесләре.

ҮЛМИ ДӘ, ҮСМИ ДӘ... Бик нык гайрәтне кайтара торган, озакка сузылган эшкә карата әйтелә / *Авылыбызда бер гаиләдә өч бала – ике кыз 1 малай тәрбияләнә. Дүртенчегә бәби алып кайталар. Яз ахыры. Авылда эш күп. Әтиләре эшне болай бүлә: малай абзарларны чиста тотарга да сыерны көтүгә куып каршыларга: икенче кызга идән себерергә дә каз бәпкәләрен карарга; олы кызга бәбине карарга. Җәй ахырларында бу кыз, көннәр буе уйнарга да чыгалмыйча бәби карый, күрше әбисе янына бала арбасы төртеп килеп утыра да: ” Сыерны куасың да көн буена тынасың, бәпкәләр дә үсеп елга буена китте. И әби, бу бит НИ ҮСМИ, НИ ҮЛМИ...” дип елап җибәрә.* /

УРМАНГА КАРАГАН ИДЕМ ШУЛ Кирәкмәгән шаһитлыктан качу өчен әйтелә торган гыйбарә. / *Авылның көньягындагы кырда бер төркем колхозчы хатыннар үзләренә бүлеп бирелгән кишәрлекләрендә чөгендер кыралар. Авыл кырыендагы Катнаш азык заводы складыннан шикле машиналар чыгып китүен күреп калалар. Берсен-берсе уздырып сөйлиләр. Кайткач беләләр, складны талаганнар. Милиция килә, апалардан сорау ала башлый. Барысы да узышып-узышып сөйли. Бары бер апа гына “И энем, мин күрмәдем, УРМАНГА КАРАГАН ИДЕМ ШУЛ”, - ди. Тегеләр ярты кышка кадәр өч көнгә бер я судка, я күрсәтмә бирергә район үзәгенә йөргәндә, бу апа чөгендерен алып бетерә.*/

**Әлеге сәхифәне 6 нчы сыйныф укучысы Зиганшин Ранис әзерләде, материаллар интернет һәм вакытлы матбугат битләренннән, төбәкне өйрәну буенча эшләнүче проекттан алынды.**

**“Караш” газетасының әлеге саны өчен җаваплы: Газимзянова Р. Г.**
**Хәбәрләшү өчен телефон: 9274825605**